МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.04.2020 Казан ш. № под-513/20

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең админис-тратив регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезендә боерык бирәм:

1. Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.
2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (В.О.Васильева) боерыкны имзалаганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Әсәдуллинага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр Р.Т.Борһанов

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 8 апрелендәге под-513/20 номерлы боерыгы белән расланды

**Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып уллыкка алучылар, опекуннар (попечительләр), тәрбиягә бала алган ата-аналар тора, түбәндәгеләр исәбеннән:

а) Россия Федерациясе территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары;

б) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар, шулай ук качаклар;

в) Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча яшәүче һәм чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның вакытлыча эшкә яраксызлык очрагына һәм ана булуына бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминиятләштерелергә тиешле затлар;

г) контракт буенча хәрби хезмәт узучы, эчке эшләр органнарында, милли гвардия гаскәрләрендә, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, җинаять үтәтү системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, таможня органнарында рядовой һәм җитәкче состав һәм, Россия Федерациясенең халыкара килешүләрендә каралган очракларда, чит ил территорияләрендә булган Россия Федерациясе хәрби формированиеләренең гражданлык персоналы сыйфатында хезмәт узучы Россия Федерациясе гражданнары.

1.2.1. Мөрәҗәгать итүчеләр исеменнән Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышаныч кәгазе нигезендә гамәл кылучы затлар эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: ТР, Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 3 йорт, 205, 207 кабинетлар.

Министрлыкның эш графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбедән тыш, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән

17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.30 сәгатьтән 13.30 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбедән тыш, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.30 сәгатьтән 13.30 сәгатькә кадәр.

Җәмәгать транспортында «Ирек мәйданы», «КАИ», «Үзәк стадион» тукталышына кадәр килергә кирәк.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Белешмәләр өчен телефоннар: 294-95-67, 294-95-18.

1.3.3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://www.mon.tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Министрлык һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – күпфункцияле үзәк) урнашкан урын һәм аларның эш графигы турындагы мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның һәм күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан мәгълүмат стендлары аша.

Стендта Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.mon.tatar.ru);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru).

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ формасында да) мөрәҗәгать иткәндә;

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

1.3.5. Министрлык урнашкан урын, аның белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы турында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк урнашкан урын һәм аның эш графигы турындагы мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы);

Россия Федерациясе Гаилә кодексы (алга таба – РФ Гаилә кодексы);

«Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» 1995 елның 19 маендагы 81-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 81-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, №21, 1929 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №17, 1755 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №15, 2036 статья; №27, 3880 статья; 2013, №27, 3477 статья; 2014, №11, 1098 статья; №26, 3390 статья кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләрен билгеләү һәм түләү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2009 елның 23 декабрендәге 1012н номерлы боерыгы белән расланган Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләрен билгеләү һәм түләү тәртибе һәм шартлары (алга таба – Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 1012н номерлы боерыгы) (Россия Юстиция министрлыгында 2009 елның 31 декабрендәге 15909 номеры белән теркәлгән);

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (алга таба – ТР Гаилә кодексы);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, №2, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 елның 8 маендагы 287 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 287 номерлы карары белән расланган Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, №19-20, 27 май, 2009 ел);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары

җыентыгы, 2010, №46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмалар яки аларның хезмәткәрләре тарафыннан мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдаланганда аның бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле мөрәҗәгать белән яки 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар белән хезмәттәшлек итү мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актларга һәм хезмәттәшлек итү турында килешүгә туры китереп күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр шуларга нигезләнеп кертелүче документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать күздә тотыла. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене түләү | 81-ФЗ номерлы федераль законның 12.1, 12.2 статьялары;<br>48-ФЗ номерлы федераль законның 31 статьясы<br>Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 1012н номерлы боерыгы белән расланган Тәртип |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 268 номерлы карары белән расланган нигезләмәнең 3.3 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү һәм түләү турында (пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында) карар.<br>Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене түләү | 81-ФЗ номерлы федераль законның 12.1, 12.2 статьялары<br>Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 1012н номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 37 |

| | | |
|---|---|---|
| | | пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү (теркәү) датасыннан башлап 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче килгән көнне бирелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта буенча, электрон адреска яки смс-хәбәр итеп) җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла | Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 1012н номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 37 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче | 1) пособие билгеләү турында гариза;<br>2) уллыкка алу турында суд карары күчермәсе яки опека һәм попечительлек органы карарыннан балага опека (попечитель) билгеләү турында, шул исәптән тәрбиягә бала алган гаилә турында килешү буенча да, өземтә;<br>3) инвалидлык билгеләү фактын раслаучы белешмә – инвалид баланы уллыкка алган затлар өчен;<br>4) балаларның туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы | Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 1012н номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 34 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | документлар – бертуган ир һәм (яки) кыз туганнарны уллыкка алган затлар өчен.<br>Әлеге графаның өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән документлар, суд карарында бала (балаларның) инвалидлыгы, шулай ук уллыкка алынган балалар арасында туганлык турында мәгълүмат булмаган очракта, тапшырыла.<br>Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү өчен, опека (попечитель) билгеләнгән очракта яки тәрбиягә алучы гаиләгә тапшырылганда, ата-аналарның (бердәнбер ата-ананың) булмавын яки алар (аның) тарафыннан балаларны тәрбия кылу мөмкинлеге булмавын раслый торган тиешле документларның күчермәләре өстәмә рәвештә тапшырыла:<br>1) ата-аналар үлеме турында таныклык;<br>2) ата-ана хокукыннан мәхрүм итү (ата-ана хокукларын чикләү турында), ата-аналарны эшкә сәләтсез (чикләнгән рәвештә эшкә сәләтсез), билгесез югалган яисә вафат булган дип тану турында суд карары;<br>3) эчке эшләр органыннан яисә опека һәм попечительлек органыннан бирелгән, табылдык (ташлап калдырылган) баланы табу турында документ;<br>4) билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән баланың уллыкка (кызлыкка) алынуына ризалык турында ата-аналар гаризасы;<br>5) ата-аналарның сак астында торуы яки ата-аналар җәза үти торган тиешле учреждениедән бирелгән, аларның иректән мәхрүм ителү рәвешендә җәза үтәве турында белешмә; | Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 1012н номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 35 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | 6) балага ата-ана кайгыртуы булмау (шул исәптән ата-ананың авыруына бәйле рәвештә дә) фактын билгеләү турында яки бала туу турындагы акт язуыннан ата-ана(лар) турындагы белешмәләрне төшереп калдыру турында суд карары;<br>7) эчке эшләр органнарыннан эзләнә торган ата-аналарның урнашу урыны билгеләнмәгәнлеге турында белешмә;<br>8) шәхесен таныклый торган документны күрсәтмәгән ананың баласын бала туган һәм бала тудырганнан соң ана кеше мөрәҗәгать иткән медицина оешмасында калдырып китүе турында акт;<br>9) «анасы» һәм «атасы» дигән юлларда сызыклар торган туу турында таныклык.<br>Даими рәвештә Россия Федерациясе территориясендә яшәүче, Россия Федерациясендә вакытлыча яши торган һәм вакытлыча эшкә сәләтле булмау һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминиятләштерүгә тиешле чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар, шулай ук качаклар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:<br>1) шәхес таныклый торган документ күчермәсе, шул исәптән яшәргә рөхсәт бирелүе турында тамга белән;<br>2) вакытлыча яшәү өчен рөхсәт күчермәсе;<br>3) хезмәт кенәгәсенең тиешле рәвештә расланган күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр яки тиешле тәртиптә таныкланган хезмәт килешүе күчермәсе;<br>4) качак таныклыгы күчермәсе. | Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 1012н номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 36 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (алга таба – Бүлек) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин, бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырыла (җибәрелә):<br>шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турында тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп.<br>Гариза һәм теркәлә торган документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Документларны электрон рәвештә тапшыру өчен аларның 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон рәвештә имзаланган булуы мәҗбүри шарт булып тора | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле булган, дәүләт | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>баланың яшәү урыныннан аның опекун (попечитель), тәрбиягә алган ата-аналары белән бергә яшәве турында белешмә (РФ Эчке эшләр министрлыгыннан); | |

| | | |
|---|---|---|
| органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; шушы документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | балага айлык пособие түләүне туктату турында халыкны социаль яклау буенча территориаль орган белешмәсе (ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан);<br>Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органыннан иминиятләштерүче сыйфатында Фонд органнарында теркәү турында белешмә яки качак таныклыгы күчермәсе (РФ Социаль иминият фондының ТР буенча төбәк бүлеге дәүләт учреждениесеннән).<br>Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Мөрәҗәгать итүчедән югарыда санап үтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела. | |
| 2.7. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре каралмаган.<br>Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү турындагы гаризага кирәкле барлык документлар да беркетелмәгән очракта, баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү һәм түләү вәкаләте бирелгән орган баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие сорап мөрәҗәгать иткән затка өстәмә нинди документлар тапшырылырга тиешлеге турында язмача аңлатма бирә. Әгәр | Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 1012н номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 38.3 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | мондый документлар тиешле аңлатма алынганнан соң алты айдан соңга калмыйча тапшырыла икән, баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие сорап мөрәҗәгать итү көне дип баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү турында гариза кабул итү (теркәү) көне яки бу гариза җибәрелгән урын буенча федераль почта элемтәсе оешмасының почта штемпелендә күрсәтелгән дата санала. | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.<br>Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре каралмаган | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм аны алу нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган | Гариза һәм документлар кергән вакыттан башлап бер көн эчендә<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 1012н номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 38.1- |

| | | |
|---|---|---|
| оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Барлык кирәкле документларны теркәп, рәсми мөрәҗәгать почта аша алынган очракта, мөрәҗәгать итү көне дип федераль почта элемтәсе оешмасының почта штемпелендә күрсәтелгән дата санала | 38.2 пунктлары |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматны урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән әлеге объектларның инвалидларны социаль | Дәүләт хезмәте күрсәтү тиешле күрсәткечләр белән җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучыларны кабул итү махсус бүлеп бирелгән урыннарда гамәлгә ашырыла:<br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;<br>документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель белән;<br>мәгълүмат стендлары белән.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән сыйфатлана:<br>документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләр аларны тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытларын бозулар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләре | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, җирле үзидарәнең үтәү-боеру органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки аннан файдалана алмау | гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезле шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләренең мөрәҗәгать итүчеләргә карата дорфа, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>мөрәҗәгать итүченең Бүлек белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча), ә мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган кирәкле барлык документлар тапшырылган очракта, хезмәттәшлек итү зарурлыгы юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Мөрәҗәгать итүче белән эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.<br>Күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең читтәге эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча Министрлыкка тапшырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Министрлык һәм күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе | |

| | | |
|---|---|---|
| | күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка, күпфункцияле үзәккә телдән (шәхсән яисә телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук «Интернет» челтәрендә Министрлык, күпфункцияле үзәк сайтыннан алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплексны мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Консультация шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша (mon@tatar.ru) электрон хәбәр рәвешендә бирелергә мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.mon.tatar.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алынырга мөмкин.<br>Гариза һәм теркәлә торган документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Документларны электрон рәвештә тапшыру өчен аларның 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон рәвештә имзаланган булуы мәҗбүри шарт булып тора.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза һәм документлар күпфункцияле үзәк, читтән торып эшләү урыны аша тапшырылган очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, читтән торып эшләү урыны хезмәткәре консультацияли, | |

| | | |
|---|---|---|
| | документларны кабул итә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат бирә. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

2) мөрәҗәгать итүчене кабул итү, документлар кабул итү;

3) ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турында карар кабул итү яисә бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында карар кабул итү;

5) баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене түләү;

6) техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү.

Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен, шәхсән, ышанычлы заты аша турыдан-туры телефон, электрон почта (mon@tatar.ru) аша һәм (яки) хат белән Бүлеккә мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, консультацияли һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләү, кисәтүләр.

3.3. Мөрәҗәгать итүчене кабул итү, документлар кабул итү.

Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документлар турыдан-туры Бүлеккә, күпфункцияле үзәк аша тапшырылырга, почта элемтәсе ярдәмендә, шулай ук электрон

чаралардан файдаланып яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы ярдәмендә электрон документ формасында җибәрелергә мөмкин.

Гариза һәм кирәкле документлар вәкаләтле органга җибәрү фактын һәм датасын раслау мөмкинлеген бирә торган ысул белән почта элемтәсе ярдәмендә вәкаләтле органга җибәрелә. Бу очракта гаризага кирәкле документларның таныкланган күчермәләре теркәлә.

Кабул итүче Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

документларның булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә (документларның күчермәләренең тиешенчә рәсмиләштерелүен, документларда чистартылган, өстәп язылган, сүзләре сызылган урыннарның һәм алдан сөйләшенмәгән башка төзәтү урыннарының булу-булмавын) туры килүкилмәвен тикшерә.

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү турындагы гаризага кирәкле барлык документлар да беркетелмәгән очракта, баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү һәм түләү вәкаләте бирелгән орган баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие сорап мөрәҗәгать иткән затка өстәмә нинди документлар тапшырылырга тиешлеге турында язмача аңлатма бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы, язу.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.4.1. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

баланың яшәү урыныннан аның опекун (попечитель), тәрбиягә алган ата-аналары белән бергә яшәве турында белешмә (РФ Эчке эшләр министрлыгыннан);

балага айлык пособие түләүне туктату турында халыкны социаль яклау буенча территориаль орган белешмәсе (ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан);

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органыннан иминиятләштерүче сыйфатында Фонд органнарында теркәү турында белешмә яки качак таныклыгы күчермәсе (РФ Социаль иминият фондының ТР буенча төбәк бүлеге дәүләт учреждениесеннән).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек итү органы белгечләре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр, рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап нәтиҗәсе булып торган мәгълүматлар (документлар) яки сорала торган белешмәләрне бирүдән баш тарту турында хәбәр.

3.5. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Алынган мәгълүматлар нигезендә Бүлек белгече:

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турында карар проекты яисә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты әзерли;

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турында карар проекты яисә баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында карар проектын рәсмиләштерә (билгеләү турында карар кабул ителгән очракта);

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турында карар проекты яисә баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында карар проектын имзалау өчен җитәкчегә (ул вәкаләт биргән затка) җибәрә (билгеләү турында карар кабул ителгән очракта).

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач ике көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җитәкчегә (ул вәкаләт биргән затка) имзалау өчен юнәлдерелгән проектлар.

3.5.2. Җитәкче (ул вәкаләт биргән зат) баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турында карар проекты яисә баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм җүләүдән баш тарту турында карар проектын раслый, имзалый һәм мөһер белән таныклый

(билгеләү турында карар кабул ителгән очракта). Имзаланган документлар Бүлек белгеченә җибәрелә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура проектлар раслау өчен килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында имза салынган хат.

3.5.3. Бүлек белгече:

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турында карарны яисә баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы карарны дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы карарларны теркәү журналында терки (баш тарту турында карар кабул ителгән очракта);

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында, баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү яки баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында хәбәр итә

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итү.

3.6. Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене түләү.

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене түләү Министрлык тарафыннан мөрәҗәгать итүченең кредит оешмасында ачылган шәхси счетына яисә мөрәҗәгать итүченең гаризада күрсәтелгән федераль почта элемтәсе оешмасы аша башкарыла.

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене түләү Министрлык тарафыннан барлык кирәкле документлар белән гариза кабул итү (теркәү) датасыннан башлап 10 көн узганчы гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең кредит оешмасында ачылган шәхси счетына яисә мөрәҗәгать итүченең гаризада күрсәтелгән федераль почта элемтәсе оешмасы аша баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособиене түләү.

3.8. Техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

Бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турындагы карарны (бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы карарны) яңадан рәсмиләштерү бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турындагы карарда (бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы хатта) җибәрелгән техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турындагы карарны (бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы карарны) яңадан рәсмиләштерү техник хатасы булган, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган документ (мондый документ бирелгән очракта) белән теркәлгән гариза (гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка 2 нче кушымтада китерелә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.1. Бүлек белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки;

бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турындагы карарны (бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы карарны) яңадан рәсмиләштерә;

бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турындагы үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны (бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы карарны) имзалау өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрә;

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турында (бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында) Бүлек җитәкчесенә имзалау өчен юнәлдерелгән, яңадан рәсмиләштерелгән карар проекты.

3.8.2. Җитәкче (ул вәкаләт биргән зат) бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турындагы (бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы) яңадан рәсмиләштерелгән карарны раслый, имзалый һәм мөһер белән таныклый һәм аны Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турындагы (бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы карар) карарны имзалау

өчен җибәргәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турында (бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар.

3.8.3. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләү һәм түләү турында (бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү һәм түләү турында (бер тапкыр бирелә торган пособиене билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклаудан һәм бетерүдән, дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә тикшерүләр уздырудан, карарлар кабул итүдән һәм учреждение вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүдән тора.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре булып түбәндәгеләр тора:

дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча документларның проектларына хокукый экспертиза уздыру. Экспертизалар нәтиҗәсе булып проектларга имза салу тора;

эш алып барылышына карата билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган тикшерүләр;

дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырылганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә гамәлләр

кылуны тикшереп тору максатларында опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырылырга мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган белгеч, эш башкару хезмәте белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның сроклары, эзлеклелеге һәм эчтәлеге бозылу очраклары һәм сәбәпләре турында белгечләр кичекмәстән дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган җитәкчесенә хәбәр итә, шулай ук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрә.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге Бүлек турындагы нигезләмәдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Бүлек җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында каралуын контрольдә тота.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгән кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр өчен җаваплы башкаручылар законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы була.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Бүлек эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр – күпфункцияле үзәк җитәкчесенә, күпфункцияле үзәк карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка белдерелә.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризасын теркәү вакыты бозылганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән бүтән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте

күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mon.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең (http://mfc16.tatarstan.ru/) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функция-ләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына яки мондый төзәт-мәләрне кертү буенча билгеләнгән вакыт бозылуга карата шикаять белде-релгәндә – аны теркәгән көннән соң биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең яки хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче

органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынуы каралмаган түләүләрне мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6. Әлеге Регламентның 5.5 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача формада яки, аның ихтыярына карап, электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсез-лекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

## 6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны эз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) документлар белән гаризаны Министрлыкка җибәрү;

6.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәкнең hh://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы заты аша яки электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урынына документлар тапшыра.

Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү турында гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә. Электрон формада килгән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

6.3.2. Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

5.4. Гаризаны Министрлыкка җибәрү.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре гаризаны һәм тапшырылган документларны Министрлыкка җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык (Бүлек) белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламенты белән җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, Министрлык (Бүлек) белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – Министрлыкка юлланган гариза.

6.5. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Мөрәҗәгать итүче җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турындагы гаризаны күпфункцияле үзәккә шәхсән яки ышанычлы заты аша тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган хезмәткәре күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.6. Техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны Министрлыкка юллау.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы эш

көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны Министрлыкка җибәрә.

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына

_____________________________________________,
(законлы вәкилнең яки ышанычлы затның Ф.И.А (булган очракта))

яши торган (теркәлү) адресы:

_____________________________________________

_____________________________________________

Чынлыкта яши торган адресы:

_____________________________________________

_____________________________________________

паспорт: серия ________ номер _____________

бирелгән «____» __________________________

_____________________________________________

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү һәм түләү турында

ГАРИЗА

Миңа баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләвегез турында үтенәм

______________________________________________________________________

(баланың фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Пособиене күрсәтелгән ысулларның берсе ярдәмендә түләвегезне сорыйм:

кредит оешмасына күчерергә ____________________________________________

______________________________________________________________________

(пособие күчерелергә тиешле оешманың атамасы, банк идентификация коды (БИК), салым түләүченең идентификация номеры (ИНН) һәм оешманың урнашкан урыны буенча салым органында исәпкә алганда бирелгән исәпкә кую сәбәбе коды (КПП), пособиеләрне алырга хокукы булган затның счет номеры) түбәндәге адрес буенча җиткерергә ____________________________________________________.

(адрес, почта элемтәсе оешмасы)

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1. ________________________________________________________________

2. ________________________________________________________________

3. ________________________________________________________________

4. ______________________________________________________________________

_______________ ________________________

(дата) (имза)

Гариза законлы вәкил яки ышанычлы зат аша тапшырыган очракта, гаризада өстәмә рәвештә түбәндәгеләр күрсәтелә:

_____________________________________________________________________________

(законлы вәкилнең (ышанычлы затның) фамилиясе, исеме, ата исеме, яшәү урыны (тору урыны, фактта яшәү урыны) почта адресы)

_____________________________________________________________________________

(законлы вәкилнең (ышанычлы затның) шәхесен таныклаучы документның атамасы, номеры һәм сериясе)

_____________________________________________________________________________

(законлы вәкилнең (ышанычлы затның) шәхесен таныклаучы документны биргән оешма һәм аны бирү датасы турында белешмәләр)

_____________________________________________________________________________

(законлы вәкилнең (ышанычлы затның) вәкаләтләрен раслый торган документның атамасы, номеры һәм сериясе)

_____________________________________________________________________________

(законлы вәкил (ышанычлы зат) вәкаләтләрен раслый торган документны биргән оешма һәм аны бирү датасы турында белешмәләр)

_______________ _____________________________________________________

(дата) (законлы вәкил, ышанычлы зат имзасы)

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына

__________________________________________,
(законлы вәкилнең яки ышанычлы затның Ф.И.А (булган очракта))
түбәндәге адреста яшәүче:
___________________________________________
___________________________________________
паспорт: серия ________ номер _____________
бирелгән «____» __________________________
___________________________________________

Киңәш ителә торган форма

Техник хата төзәтү турында гариза

Мин,____________________________________________________________
*(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, иseme, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)*
яши торган адрес: ______________________________________________________
_______________________________________________________________________
*(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)*
_______________________________________________________________________
*(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы,*
_______________________________________________________________________
*документны биргән орган аталышы)*
баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү һәм түләү турында ______________ № __________ карарда җибәрелгән ____________________ техник хатаны төзәтүегез турында үтенәм.

Техник хатаны төзәтү турында мәгълүмат алуга риза
_______________________________________________________________________
*(язмача, телефон аша, смс-хәбәр белән, электрон почта аша)*

«___» ____________ 20___ ел. _________________ ____________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен һәм аны күрсәткәндә агымдагы контрольлек өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 294-95-90 | Rafis.Burganov@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 294-95-02 | Alsu.Asadullina@tatar.ru |
| Опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге башлыгы | 294-95-66 | Venera.Vasileva@tatar.ru |

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы | 264-77-20 | Andrey.Vybornov@tatar.ru |